«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Васильево 3нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

# Якташыбыз Равил Гарәфетдин улы Сәйфетдиновның тормыш юлы, иҗаты

Васильево 3нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбенең туган тел һәм әдәбият укытучысы
Шекаева Надия Фаязовна




Яшел Үзән районы – татар халкына бик күп күренекле ул һәм кызлар бүләк иткән төбәк.



Бөек мәгърифәтчебез Каюм Насыйри да шушы районнан



Татарстанның атказанган укытучысы, Россиянең мәгариф отличнигы, Хезмәт ветераны Равил Гарәветдин улының яшүсмер еллары һәм гомеренең күп өлеше Яшел Үзән районы Мулла Иле авылында уза.



Сәйфетдинов Равил Гарәфетдин улы 1938 нче елның 14 нче октябрендә Мулла Иле авылында туган.




1956-1961 нче елларда Казан дәүләт университетында укый. Монда уку елларында үзен актив студент буларак күрсәтә : төрле кичәләрдә катнаша, шигырьләр иҗат итә.



Җәйге каникулларда ул чирәм җирләрдә эшли. Равил абыйны “ Чирәм җирләрне үзләштергәне өчен ” медале белән бүләклиләр.



Университетны тәмамлагач, аны Самара өлкәсендәге Гали авылы мәктәбенә укытучы итеп җибәрәләр. Ул монда ике ел эшли: татар, рус, немец телләрен укыта.




1963 нче елда Р.Сәйфетдинов Мулла Иленә кайта , һәм шушы көннән аның бөтен калган гомере туган авылында уза.



1968 нче елда аны директор урынбасары итеп куялар, 1971 нче елдан мəктəп директоры итеп билгелилəр. Ул 2000 нче елга кадəр директор булып эшли.



Равил Гарәфетдинович авыл тормышында, җәмәгать эшләрендә дә үзенә йөкләнгән барлык вазифаларны да җиренә җиткереп башкара: агитаторлар җитәкчесе, пропагандист, авыл Советы рәисе урынбасары, Иптәшләр Суды рәисе, комсомол секретаре, “ Белем җәмгыяте” лекторы...





Равил ага 2008 нче елдан гомеренең соңгы көннәренә кадәр Мулла Иле авылында имам-хатыйб вазифаларын да башкара.



“Мәңгелеккә килдем дип эшлә, иртәгә үләм дип гыйбадәт кыл”, - дип яши ул.



Анын эшчәнлеге бәяләнмичә калмый. СССР мәгариф министрлыгының Мактау Грамотасы, “Татарстанның атказанган укытучысы “, “Россиянең мәгариф отличнигы” дигән мактаулы исемнәр бирелә, “Хезмәт ветераны” медале белән бүләкләнә.



Мулла Иле халкы үзе олы тормышка чыгарган, соңгы тору урынын да шушында сайлаган милләт җанлы Равилен онытмый һәм киләчәктә дә онытмас, дип ышанабыз. Аның шәхесе, ул тудырган шигырьләр һәрвакыт халык күңелендә сакланыр.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт !